**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүләре һәм вазыйфалар атамалары үзгәрүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссия турында» 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 13 мартындагы ПУ-271 номерлы, 2015 елның 28 мартындагы ПУ-372 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1094 номерлы һәм 2017 елның 16 июнендәге ПУ-505 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында экологик куркынычсызлык, табигатьтән файдалану һәм санитария-эпидемиология иминлеге буенча ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Ф.С. Габделганиевны, А.Ю. Вафинны, А.Ә. Назировны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Кузюров Равил Әфраим улын – Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрын;

Садыйков Марат Наил улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын, аны Комиссия рәисе урынбасары итеп расларга;

Шадриков Александр Валерьевичны – Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрын, аны Комиссия рәисе урынбасары итеп расларга;

в) Комиссия әгъзасы Ф.С. Батковның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларның яңарып торуы һәм су культурасын үстерү мәсьәләләре буенча республика советы турында» 2016 елның 4 ноябрендәге ПУ-984 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 13 октябрендәге ПУ-910 номерлы

Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларның яңарып торуы һәм су культурасын үстерү мәсьәләләре буенча республика советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан И.Г. Вәлиевны, Ә.М. Залаковны, М.З. Шакировны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Гобәйдуллин Әгъзам Самат улын – Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисен (килешү буенча);

Ибраһимов Илнур Галим улын – «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарын (килешү буенча);

Сөнгатуллин Рөстәм Хизбулла улын – «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционер җәмгыяте генераль директорын (килешү буенча);

в) Совет әгъзасы Ю.Б. Матвеевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы турында» 2016 елның 4 ноябрендәге ПУ-985 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1090 номерлы һәм 2017 елның 20 октябрендәге ПУ-915 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы (алга таба – совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан Ф.С. Габделганиевны, Д.И. Гайнетдиновны, А.Ә. Назировны, В.Г. Шәйхразиевны, М.З. Шакировны чыгарырга;

б) Совет составына кертергә:

Богомолов Станислав Юрьевичны – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Транспортта Казан линия идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Гобәйдуллин Әгъзам Самат улын – Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы рәисен (килешү буенча);

Кузюров Равил Әфраим улын – Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрын;

Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улын – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарын, аны Совет рәисе урынбасары итеп расларга;

Шадриков Александр Валерьевичны – Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрын, аны Совет рәисе урынбасары итеп расларга;

в) Совет секретаре Р.Г. Шәрәфетдиновның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары».

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2018 ел, 14 май
№ ПУ-370